**Г.Р.Гайнуллина**

**Казанский (Приволжский) федеральный университет, Казань**

# МАРАТ ӘМИРХАНОВНЫҢ “ҮРБӘТ ХАНӘКӘ ГЫЙШКЫ” РОМАНЫНДА АВТОР ПОЗИЦИЯСЕ БИРЕЛЕШЕ

**Аннотация**. Анализ произведения выполнен с целью рассмотрения соотношений понятий “субъект художественного высказывания” и “автор литературного произведения”. Субъект художественного высказывания входит в структуру автора литературного произведения и выступает как принцип обнаружения “чужого слова”.

**Summary**. Analysis of the work is made to consider the relationships between the concepts "subject of artistic expression" and "author of a literary work". The subject of artistic expression enters the structure of the author's literary work and serves as the detection principle of the "foreign word".

**Ключевые слова** автор позициясе, персонажлар сөйләме.

**Key words** author position, talking of characters.

Марат Әмирхановның “Үрбәт ханәкә гыйшкы” (2005-2006) романында әсәрнең сюжет, вакыйгалар катламын үз тирәсенә җыеп, автор концепциясен белдерүче төп героиня морза кызы Үрбәтнең уй-кичерешләре тасвирлана. Романның иҗтимагый сюжет сызыгын автор тарихи вакыйгаларга нигезләнеп кора. Вакыйгалар Мөхәммәдәминнең тәхеткә килеп, ханлыкның үз эчендә һәм Мәскәү белән гадел, тигез мөнәсәбәтләр урнаштырырга омтылышы кебек үстерелә. Иң киеренке нокта – ханның авырып китүе, тәхеттән ваз кичүе, 1517 елның 19 ноябрендә Габделлатыйфның үтерелүе, ханның тәхеткә кайтуы. 1518 елның 22 декабренда ханның вафат булуы белән конфликт чишелә.

Автор карашы дәүләтне ныгыту проблемаларының яктыртылуында ярылып ята. Мөхәммәдәминнең “Үзен үзе саклый алмаган дәүләтнең эчке халәте дә була алмый” [1:65] – дип белдерүе автор позициясе кебек кабул ителә. 1980-2000 нче елларда язылган тарихи романнарда яңгыраган карашны дәвам итеп, М.Әмирханов дәүләтнең ныклыгын дин билгели, дигән карашта тора: “Баш кешене олылау – Аллаһыны олылау дигән сүз. Чөнки баш кеше, ягъни дә

хан – Күкләр ихтыяҗын башкаручы зат. Бүгенге затыбыз исә шанлы Чыңгызлар ыруыннан килүче Олугъ Мөхәммәд бине Мөхәммәд бине Ибраһим бине Мөхәммәдәмин булыр. Аның хакимлеге чорында барча Казан җире тыныч һәм мул тормыш кичерсен” [1:38]. Мөхәммәдәмингә мәчеттә хан бүреген кигерү вакыйгасында автор позициясе әдәби детальләргә басым ясау аша җиткерелә. Дин мәсьәләсендә Уйгын бәк белән Сәед бәхәсенә ханның нокта куюы автор фикерен ныгытып куя: “Дога – мөселманның байрагы ул!” [1:91]. Иванның улы Василийга соңгы киңәшендә дә дин – дәүләтнең нигезе дигән автор позициясе кабатлана: “Православие – дәүләтнең нигезе, аны минем шикелле санла, еретикларга көн күрсәтмә, эзәрлеклә” [1:95]. Үрбәтнең уйлары кебек оештырылган хикәяләүче сөйләмендә дин турындагы фикеркабатлана: “Әсирлек язмышын кабул итсә дә, динен алыштыруга теше-тырнагы белән каршы ул. Ничек үз асылыңны үзгәртмәк кирәк? Бу соң сиңа тормыш биргән, сине бар иткән ата-анаңны алыштыру булыр иде ләбаса. Ә ата-ана – алыштыргысыз” [1:11].

Романда автор татар хатын-кызының камил образын тәкъдим итә. Романның шәхси сюжет сызыгында вакыйгалар катламына “Казан йортның иркә хуҗабикәсе, алтын-көмеш, ука-чука, асылташ, сый-нигъмәт, кадер-хөрмәт эчендә йөзәргә тиешле” [1:6] Үрбәт мәхбүслек язмышы белән килешкән образ буларак килеп керә. Ханәкәнең башкалар белән мөнәсәбәтләре кечкенәдән күнектерелгән гадәтләренә бәйле. Унбер яшендә ир хатыны булган кыз “горур булырга, бил бөкмәскә” [1:6] өйрәтелгән. Үзен берөзлексез кимсеткән каенанасы Фатыйма-солтанга да ачу сакламый, хәленә төшенә: “Баксаң, мәрхүмәне, карт бичә була торып, кечкенә хатын, дип йөрткән икән казанлылар: түбән ыруга мөнәсәбәтле ишарә”[1:8]. Үрбәт-Фатыйма-солтан мөнәсәбәтләренә бәйле рәвештә авторның әхлакый позициясе белдерелә: “Башкаларны рәнҗетү бәрабәренә генә абруй казанып булса иде дә! Юк шул! Кылган гамәлләрең иртәме-соңмы үзеңә китереп суга” [1:8]. Үрбәт образын ачарга ярдәм итүче персонажлардан Мөхәмәдәминнең сеңлесе Гәүһәршадны аерып карарга мөмкин. “Озынча нәфис йөзле, тулы иренле яшь ханым” һәм

Үрбәт икесе дә усал, булдыклы, акыллы (урыс патшасының күрәзәчесе Аграпина Үрбәтне шулай сыйфатлый) һәм “көнче, кылтыклар” [1:108]: “Хәер, аш-су, кием-салым белән генә чикләнми бу мөхтәрәм бикәләрнең мәшәкатьләре. Дәүләт эшләренә дә куллары җитә аларның” [1:108]. Гәүһәршад исә “үзсүзле, тәвәккәл. Ходай аңа акылны өеп биргән. Дуамалга һич тузынмас, адәмне юкка-барга рәнҗетмәс” [1:106]. Хан нәселеннән булмаган Булат бәкне ир итеп үзе сайлап, автор карашынча, “бөтен мөселман дөньясында булмаганны булдыра” [1:108]. Нурсолтан образы да Үрбәт образы белән янәшә куела: “Нурсолтанның ил гизү белән мавыгуы, мөгаен, ат яратуыннан киләдер” [1:130]. Татар хатын-кызы – горур дала кызы, дип гомумиләштерә автор: “Дала – ат иле” [1:130]. Дала кызы “теләсә кемне үз иркенә буйсындыра ала” [1:144], дигән караш белдерелә “күк кабагы ачылуын күргән”, “елдырым таш иясе” Нурсолтан образы аша. Үрбәтнең атының кушаматы Күбәләк булу да юкка түгел. Иң киеренке вакытта бүреләрдән саклап кала алган елгыр тай “җиһанга изге гамәлләр кылыр өчен яратылган бикәсенә” [1:24] охшаган. Мифологик мотив Үрбәт ханәкә образын тулыландыра: “Кырыкламаң вакытында тәнеңнән көлтә-көлтә нур чәчелде, – диде Бәхиҗә түшәкче, – суны башыңа кырык кашык белән үзем коеп тордым. Кашыклары көмеш иде” [1:8]. Кош мифологик образы “җан” [3:161] мәгънәсендә килә (кызның сөйгәненә бүләк иткән кульяулыгындагы ике һомай кошы дип тагын бер кабатлана), автор шул рәвешле хатын кичерешләрендә үзгәрешләр көтелүен хәбәр итә. “Киң җилкәле, кырыс йөзле” Мөхәммәдәмин кыз күңелендәге тойгыларын алыштыра да куя: “Кайчан гына “гомерем ахырына якынлашты, иманыма тугры калып, догада килеш өзелсәм иде”дип теләк тели иде ул. Хәзер гыйшык утында яна” [1:25].

Автор Үрбәтнең яратуын илаһилаштырып сурәтли. Сөеклесенә зөфаф кичендә кульяулык бүләк итүе, күк төймә турында әкият сөйләве, ире белән һәр очрашуга әзерләнүе, кабал сугуы, җыру җырлавы – татар кызларына хас күркәм гадәтләр кебек гомумиләштерелә. Татар хатыны ирен яратып көйли, сак кына ярдәм итә, үстерә, дөньяга карашын киңәйтә, ди автор ханбикә образы аша. Мөхәммәдәмин хан кичерешләрендә үзгәрешләр Үрбәт ханәкә гыйшкы

йогынтысында була. Яшьли ятим калган, “бик иртә тәртә арасына кергән”, “олуг кенәз Иван Васильевич кулына килеп эләккән” Мөхәммәдәмин утыз өч яшьтә яратуны танып үзгәрүе очраклы түгел. Әсәргә ир-атның утыз өчтә сынау кичеререгә тиешлеге хакындагы ышану килеп керә. Ышану Гайсә пәйгамбәр турындагы мифка барып тоташа. Мөхәмәдәмин образы эшләнешендә тормыш мәгънәсен аңлатып килгән дәрья мотивы катнашуы да символик укылышлы.

“Мәшһүр Туктамыш хан ыруыннан килгән Алтын Урда ханы олуг Мөхәммәтнең оныкчасы” Үрбәт ханбикә образына матур гадәтләрне генә түгел, дәүләтне саклап калу вазифасы да йөкләнә. Алтын Урда чорында ханнарны киезгә менгерү йоласын кабат кайтарырга теләве Мөхәммәдәмин ханда үткәннәргә бәйле горурлык хисләрен уяту теләге белән бәйле: “Казан ханлыгына синең бабаң Олугъ Мөхәммәд нигез салган, бөек дәүләтләр сафына бастырган. Син шул юлны дәвам иттерүче. Элекке дан, элекке шөһрәтне кайтаруны да Ходай сиңа язган дип беләм. Казан йорты әүвәлгечә бөтен тирә-якны куркытып, дер селкетеп торсын иде” [1:39]. Бу автор карашы дип кабул ителә.

“Казан-йорт – барыбызның да гомер бишеге” [1:66], дип ирен көйләп торучы Үрбәт Мөхәммәдингә кыл байрак тоттыра – олуг хан итә. Дәүләтне аның хакимнәре ныгыта, дигән автор карашы Мөхәммәдәмингә бәйле дә, Иван III гә бәя буларак та гел яңгырап тора. Мөхәммәдъяр шагыйрь образы да Мөхәммәдәминне бәяләп килеп керә. Ун яше тулмаган “калын иренле, тавык йомыркасы шикелле озынчарак битле малай” белән хан “Йосыф кыйссасы” телендә сөйләшә. Нәни шагыйрь образына хакимнәрнең дәүләт алдында җаваплылыгы турындагы фикер әйтү йөкләтелә: “Җиһан алар кулында бит, алардан күп нәрсә тора” [1:123]. Бу фикерне ханлыктагы тәртипселекләргә бәйле Мөхәммәдәмин кабатлый: “Хөкүмәтне тәгаенләү – хан вазифасы” [1:179].

Ханның малайга әйткән васыяте авторның чын татар ире нинди булырга тиеш, дигән сорауга җавабы кебек укыла: “Ышанам, син татарның күренекле шәхесе булырсың, морза, шигырь чыгару Ходай фарыз кылган иҗтиһад ул. Тик ир-егет шуның өстенә кулына корал тотып туган илен дә саклый белергә тиеш.

Монысы минем сиңа васыятем" [1:123]. Мөхәммәдәминнең гыйлемлелекне хуплавы, шуның өстенә "зирәк балалар өчен дөньяви мәктәп ачуы" турында әйтелү – дәүләт башлыгы ия булырга тиешле сыйфатлар турында автор карашы. "Киләчәк – дөньяви фәндә" [1:124] дигән алдынгы карашлы татар ханы һәм бәге белән горурланырга чакыра әдип. Хан мәҗлесендә "Йосыф кыйссасын" әйтүләр, фарсы, төрки чыгышлы әдипләрне искә алулар да автор позициясен ныгытып куярга ярдәм итә.

Гаделлеккә бәйле караш Мөхәммәдъяр шигырьләрендә, Нурсолтан-Үрбәт бәхәсендә белдерелә. Нурсолтан кешеләр туганда ук бүленеп куя, дигән карашны үткәрә, гаделлек ханга кагылмый, дип саный. Бу фикерне рамазан ае мәҗлесендә хан үзе дә кабатлый: "Мин – хан! Шагыйрь башка, хан  башка. Шагыйрь – гаделлек җырчысы. Ә хан гадел була алмый. Хан – дәүләти мәнфәгатьләр колы" [1:176]. Үрбәт исә ханның гаделлеккә омтылышын теләр иде. Авторның Үрбәт карашын яклавы сизелә. Үрбәт йогынтысында Мөхәммәдәмин дәүләтнең идарә өскормасын камилләштерү нияте белән яши башлый (хөкүмәт әгъзаларын үзеңә сайлап алу хокукы кертүе, корылтайны гади халыкны идарәгә якынайту өчен киңәйтүе). Ханның үлем түшәгендә гаделлек хакындагы хакыйкатьне белдерүе автор позициясен ныгытып кую өчен кирәк: "Ходай каршында гавам тигез. Ул инсаннарны аксөякләргә һәм кара халыкка, байларга һәм ярлыларга, ир-атка һәм хатын-кызга аерып карамый. Аңа патша да, көтүче дә бер. Бу – гаделлекнең иң бөек тантанасы [1:216].

Нәтиҗә ясап, романда  И.В.Саморукова тәкъдим иткән "киң мәгънәдәге автор" [2:18] категориясе алга алына, дигән фикер тамгалап куела ала. Бу категория "автор категориясенең тар мәгънәсеннән" персонаж сүзен үз сүзе кебек тәкъдим итүе белән аерылып тора.

Кулланылган әдәбият


1. Әмирханов М. Үрбәт ханәкә гыйшкы / И кылган догам минем: роман, повесть. – Казан: Татар. кит.нәшр., 2008. Б.7-276.

2. Саморукова И.В. Художественное высказывание как эстетическая деятельность: типология и структура креативного опыта в системе дискурсов. Автореф.дисс. докт. филол.н.– Екатеинбург, 2004. 43 с.
3. Урманче Ф.И. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 2 т. (Д–С). – Казан: Мәгариф, 2009. 343 б.

Персональные данные:

Гайнуллина Гульфия Расилевна

Место работы: КФУ, кафедра методики преподавания и современной татарской литературы (Казань, ул.Татарстана, 2)

Должность: доцент

Ученое звание: доцент

Название доклада “М. Әмирхановның “Үрбәт ханәкә гыйшкы” романында автор позициясе бирелеше”

Казань, Хлебозаводская, 3-8

2920130

892-767-070-66.

gulfiarasilevna@mail.ru